СОВЕТ БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР
20.09.2017 | № 28-123

с. Большие Меми

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Олы Меми авыл җирлеге Уставының 11 статьясы нигезендә ,

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Олы Меми авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрүнең уртак инициативасын тәкъдим итергә:
«Сез 2018 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә ризамы:
- Олы Меми авылы территориясендә урнашкан 200 метр озынлыктагы Я. А. Гаврилов урамнарына, 50 метр озынлыктагы Яшьләр урамына, 100 метр озынлыктагы Заречная урамына өлешчә вак таш салу
- Олы Меми авыл җирлеге территориясендә Заборная Поляна авылында урнашкан чишмә коймасын тоту

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г.А. Фомина